ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл жирлеге башлыгы

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава Старотатарско-Адамского сельского поселения Аксубаевского муниципального района

423055 Республика Татарстан Аксубаевский район с. Старый Татарский Адам, ул. Центральная дом 20
Тел. (8-84344-4-35-84) ОГРН 1021605359610,
ОКПО 27839564, ИНН/КПП 1603000965/160301001
E-mail: *Stadam.Aks@tatar.ru*

---

КАРАР

15 ноябре 2024 ел ел. № 1

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге
Иске Татар Әдәмсуы авылы
гражданнарының үзара салым акчаларын
кертү һәм алардан файдалану
мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 ел, 28 июль, 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Иске Татар Адәмсуы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 27 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Аксубай районы Иске Татар Әдәмсуы авылы Үзәк урамы, 17 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасы янында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлегенең Иске Татар Әдәмсуы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, контракт буенча хезмәткәрләрне, волонтерларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергәләп яшәүче ата-аналар, ир белән хатыннар, балигъ булган балалар)түләүдән азат итүдән тыш, 500 сум күләмендә 2025 елда үзара салым кертү һәм алдагы эшләрне башкару буенча әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1. 1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
Иске Татар Әдәмсуы торак пункты урамнары буйлап торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларың төзү, ремонтлау һәм карап тоту (вак таш, туфрак вагы сатып алу, ташу, салу, тигезләү, комнан һәм туфрактан нигез салу, эшләр өчен килешү буенча түләү); Иске Татар Әдәмсуы авылы эчендәге юлларны карап тоту, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту (килешүе буенча хезмәтләр өчен түләү).

2. Җирлек торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын үткәрүне тәэмин итү:
- янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын тоту: ягулык-майлау материаллары сатып алу).

3. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуына таләпләрне үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- урамнарны яктырту җайланмасы (торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, Иске Татар Әдәмсуы авылы урамнарында энергия саклаучы лампалар сатып алу, сатып алу, урнаштыру)
4. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:
-су белән тәэмин итү башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны, халыкка су бирүне тәэмин итә (суүткәргеч челтәрен ремонтлау, Иске Татар Әдәмсуы авылы торак пунктында гидрантлар урнаштыру (килешү буенча товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://Aksubayevo.tatarstan.ruһәмхокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга:http://pravo.tatarstan.ru/

Аксубай муниципаль районы
Иске Татар Әдәмсуы авыл
җирлеге башлыгы: Э. М. Хөснуллина